# Герой- шагыйрь Муса Җәлилнең тууына 115 ел

Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы кысаларында, герой -шагыйрь Муса Җәлилнең тууына 115 ел тулу уңаеннан “Муса Җәлил - милләт каһарманы” темасына бәйге үткәрелде.

Сыйныфтан тыш чара түбәндәге эпиграф астында оештырылды.

“Үлгәндә дә йөрәк тугры калыр,
Шигыремдәге изге антына
Бар җырымны илгә багышладым,
Гомеремне дә бирәм халкыма.”

Бу чарада 26 укучы, 2 укытучы катнашты. Кабинет Муса Җәлил портреты, шагыйрь турында материаллар тупланган альбомнар, шагыйрьнең тормыш юлын һәм иҗатын чагылдырган күргәзмә, шагыйрьнең тормышы һәм иҗаты турында презентация, Рафаэль Мостафинның “Муса Җәлил турында” видеофильмы, туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы эмблемасы белән җиһазланган иде.

Әлеге сыйныфтан тыш чараның төп максатлары булып түбәндәгеләр тора:

- Муса Җәлилнең туган илгә тугрылык хисе белән сугарылган шигырьләренең әһәмиятен ачыклау;тормыш юлын искә төшерү;
- Укучыларның эзлекле фикер йөртү сәләтен, бәйләнешле сөйләм телләрен үстерү;
- Укучыларда Муса Җәлил иҗатына һәм шәхесенә карата ихтирам, милли үзаң, горурлык хисе тәрбияләү.

Бәйге укучыларда Муса Җәлил иҗатына һәм шәхесенә карата ихтирам, милли үзаң, горурлык хисе тәрбияләү чыганагы булды.




И туган тел, и матур тел,
Әткәм-әнкәмнең теле!
Г.Тукай


15 февраля –
115 лет со дня рождения
татарского поэта
Мусы Джалиля
15 февраль – герой- шагыйрь
Муса Җәлилнең
тууына 115 ел
Муса Җәлил —
халкым улы
Песнь
о Джалиле
Муса Җәлил
Первый урок